**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы**
**Шеңшеңәр авыл җирлегенең Ор торак пунктында**
**үзара салым акчасын кертү һәм аннан файдалану буенча**
**халык җыены КАРАРЫ**

2024 елның 27 нче ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлегенең Ор торак пунктында халык җыены КАРАР бирде:

1. Үзара салым суммасының 50% күләмендә ташлама билгеләнгән 1 төркем инвалидлардан,балачактан инвалидлардан, балигъ булмаган балалар тәрбияләүче тулы булмаган гаиләләрдән, ялгыз өлкән пенсионерлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, һәм Россия Федерациясе Кораллы көчләренә мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлегенең Ор торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданга 2025 елда үзара салымны 600 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:
-традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү ( Ор авылы зиратын төзекләндерү).

3. Халык җыены нәтиҗәләрен Шеңшеңәр авыл җирлеге Советының мәгълүмати стендларында урнаштырырга, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында,Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Балтач муниципаль районы сайтында бастыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет рәисе Р.Х.Салихҗанов